Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомырбаш авыл җирлеге Советы

**7 НОМЕРЛЫ КАРАР**

Шомырбаш авылы 2019 елның 13 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендә кабул ителгән «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында 15.04.2019 ел, №63-ФЗ «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм «Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 9 статьясына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының « Шомырбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш т авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендә 11 номерлы кабул ителгән «Физик затлар милкенә салым турында» гы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 июнендәге 13 номерлы, 2015 елның 15 октябрендәге 4 номерлы, 2018 елның 30 октябрендәге 14 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 15 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1) 3.2 пунктының 12 абзацын үз көчен югалткан дип таныrга;

1.2) 3.2 пунктның 11 абзацында «1 ноябрьгә кадәр» сүзләрен «31 декабрьдән дә соңга калмыйча»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.:

- Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Шомырбаш авылы, Совет урамы, 47 йорт;

- Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Таулар авылы, Ленин урамы, 50А йорты;

- Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Алан Полян авылы, Я.Емельянов урамы, 6 йорт;

- Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Кызыл-Йолдыз урманчылыгы, Парк урамы, 10 йорт;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы” Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасының
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомырбаш авыл җирлеге башлыгы И.Н.Сафин